ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.12.2020 Казан шәһәре № 547/2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан газ куллanучы җайланмаларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү һәм (яки) аның күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләре, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган бертөр дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге турында» 2019 елның 18 сентябрендәге 2113-р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә,
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан газ куллanучы җайланмаларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү һәм (яки) аның күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары

билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2020 елның 10
декабрендәге 547/2020 номерлы
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан газ кулланучы җайланмаларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү һәм (яки) аның күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең**

# АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент газ кулланучы җайланмаларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү һәм аның күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә газ бүлү челтәренә ия булган газ бүлү оешмалары (алга таба – газ бүлү оешмалары).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Дәүләт комитеты урнашкан урын: Казан шәһәре, К.Маркс урамы, 66.

Дәүләт комитетының эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.00 башлап 17.00 кадәр, җомга 8.00 башлап 15.45 кадәр, төшке аш 12.00 башлап 12.45 кадәр; шимбә, якшәмбе – ял.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Дәүләт комитетының эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «Толстой» тукталышына кадәр килергә.

10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89, 91, 98 номерлы автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 номерлы троллейбуслар.

Керү – шәхесне таныклаучы документны күрсәтеп.

1.3.2. Дәүләт комитетының технологик ялгаган өчен түләүне җайга салу һәм контрольдә тоту бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 221-82-45.

1.3.3. Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – Дәүләт комитетының рәсми сайты) рәсми сайты адресы: http://kt.tatarstan.ru, Дәүләт комитетының электрон почта адресы: kt@tatar.ru.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен җаваплы булган Дәүләт комитеты структур бүлекчәсе хезмәткәренең электрон почта адресы: Shakirzyanova.Ilvira@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru);

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

3) Дәүләт комитетына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Дәүләт комитетына язмача мөрәҗәгать иткәндә (почта аша яисә «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы» аша).

1.3.5. Дәүләт комитеты урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Дәүләт комитетының электрон почта адресы турында мәгълүмат Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Дәүләт комитеты бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Дәүләт комитеты җибәргән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон). Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентка 1 нче, 2 нче кушымталарда китерелгән;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Идарә – Дәүләт комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү һәм бәяләрне (тарифлар) билгеләү турында карарлар һәм башка карарлар кабул итү өчен оештырылган Дәүләт комитетының коллегиаль органы;

«Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше системасы) – Татарстан Республикасында электрон документлар алмашу буенча, шулай ук Татарстан Республикасында электрон оештыру-боеру документларын булдыру, куллану, тапшыру һәм саклау өчен булдырылган дәүләт мәгълүмат системасы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Газ куллана торган җиһазларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү һәм (яки) аның күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары билгеләү (алга таба – түләү (түләү ставкасы) билгеләү) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә газ бәяләре, аны транспортлау өчен тарифлар һәм газ куллану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү формалаштыру һәм аларны дәүләт тарафыннан җайга салуның төп нигезләмәләре (алга таба – Төп нигезләмәләр), Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2018 елның 16 августындагы 1151/18 номерлы боерыгы белән расланган Газ куллану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә |

| | |
|---|---|
| | |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт ком |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Түләү (түләү ставкалары) билгеләү буенча Тат Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар түләү (түләү ставкалары) билгеләү турындагы гаризаны га чыгару турында белдерү |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын | Түләү (түләү ставкалары) чираттагы календарь чираттагы ел алдыннан 31 декабрьдән дә соңга ка билгеләнә.<br>Газ бүлү оешмасында объектларны технологик тота буенча хезмәтләр күрсәтүдән алынмыйча калган ке |

| | |
|---|---|
| да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | барлыкка килгән очракта, алар газ бүлү челтәрләре буен транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларны билгеләгәндә алынырга тиеш, чираттагы календарь елына газ челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү чираттагы елн декабреннән дә соңга калмыйча билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаг<br>Түләү (түләү ставкалары) күләмен раслау өчен к документларны, белдерү белән, җайга салучы органга га оешмасы тарафыннан җибәрмәгән очракта, ләкин түләү ставкалары) күләмен раслау өчен документлар алынган д башлап 30 эш көненнән дә иртәрәк булмаган чорда, гамәлдән чыгарыла.<br>Дәүләт комитеты түләү (түләү ставкалары) билгеләү ту карар кабул ителгәннән соң биш календарь көне эчендә рас карар күчермәсен (беркетмәдән өземтә) җайга салына тор бүлү оешмасының адресына җибәрә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрә итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, | 1. Түләү (түләү ставкалары) исәпләү өчен газ бүлү оеш җибәрә торган материаллар:<br>а) оешма паспортын теркәп, чираттагы календарь елына ставкаларын билгеләү турында гариза (1 нче кушымта)<br>Гариза газ бүлү оешмасының вәкаләтле заты тараф имзалана һәм (булган очракта) газ бүлү оешмасының белән беркетелә.<br>б) агымдагы елның 1 октябренә актуаль булган, бухгалт исәбенә алу максатларында газ бүлү оешмасының исәп сәясәте;<br>в) тоташтыру (технологик ялгау) чараларын гамәлгә өлкәсендә эшләүче газ бүлү оешмасының структур бүлек хезмәткәрләренең сан исәбе, узган календарь елы |

| | |
|---|---|
| аларны тапшыру тәртибе | хезмәткәрләрнең саны һәм хезмәт хакы турында мәгълүм булган рәсми статистик хисап формасын теркәп;<br>г) бухгалтерлык балансының һәм эшчәнлекнең җайга сал төрләре буенча чыгымнарны һәм керемнәрне аерым исәпкә финанс нәтиҗәләре турында хисап күчермәләре, к үзгәрешләре турында хисап, акча хәрәкәте турында хисап (а календарь елы өчен) күчермәләре;<br>д) тиешле календарь елы эчендә газ бүлү челтәрләрен проект документациясен эшләүгә газ бүлү оешмасы чыгы составы (3 нче кушымта), стандартлаштырылган тариф ста исәпләү тәртибе буенча аңлатма язуы (С1);<br>е) стандартлаштырылган тариф ставкасын (С2) исәпләү т буенча аңлатма язуы белән, тиешле календарь елы эчендә газүткәргечен төзүгә газ бүлү оешмасының чыгымнар сост нче кушымта);<br>ж) стандартлаштырылган тариф ставкасын (С3) и тәртибе буенча аңлатма язуы белән, тиешле календарь елы полиэтилен газүткәргечен төзүгә газ бүлү оешмасының чыг составы (5 нче кушымта);<br>з) стандартлаштырылган тариф ставкасын (С4) исәпләү т буенча аңлатма язуы белән, тиешле календарь елы траншеялы булмаган ысул белән газүткәргеч төзүгә газ оешмасының чыгымнар составы (6 нчы кушымта);<br>и) стандартлаштырылган тариф ставкасын (С5) исәпләү т буенча аңлатма язуы белән, тиешле календарь елы эчендә редукцияләү пунктларын проектлау һәм төзүгә газ оешмасының чыгымнар составы (7 нче кушымта);<br>к) стандартлаштырылган тариф ставкасын (С6) исәпләү т буенча аңлатма язуы белән, тиешле календарь е коррозиядән электрохимик (катод) яклау җайланмаларын (8 нче кушымта) газ бүлү оешмасының чыгымнар составы; |

| | |
|---|---|
| | л) мөрәҗәгать итүченең техник шартларны<br>мониторинглау өчен һәм тиешле календарь елы эчендә га<br>оешмасының газ бүлү челтәренә фактта тоташтыруны г<br>ашыру өчен газ бүлү оешмасының чыгымнар составы (<br>кушымта), стандартлаштырылган тариф ставкасын и<br>тәртибе буенча аңлатма язуын (С7) теркәп;<br>м) тиешле календарь елында башкарылган килешүләр<br>технологик тоташтыру кысаларында газ бүлү һәм газ ку<br>объектлары төзелешенә чыгымнар турында белешмәләр (1<br>кушымта), башкарылган эшләр актлары (КС-2, КС-3,<br>унификацияләнгән формалары), башкарылган эшләр а<br>булмаганда – эш төрләре буенча локаль һәм җыелма<br>хисаплары.<br><br>2. Җир кишәрлеге чикләре эчендә технологик тоташтыр<br>түләү билгеләү өчен газ бүлү оешмасы тапшыра<br>материаллар:<br>а) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүм<br>стандартлаштырылган тариф ставкасын исәпләү тәртибе<br>аңлатма язуы белән, газ куллану челтәрен проек<br>стандартлаштырылган тариф ставкасының исәпләмәсе (Спр<br>б) коррозиядән электрохимик яклау системасы җайланм<br>һәм газүткәргеч төзүгә стандартлаштырылган тариф ставка<br>исәпләмәсе ($С_Г$) һәм газ бүлү оешмасының чыгымнары т<br>мәгълүмат;<br>в) газны редукцияләү пунктын урнашт<br>стандартлаштырылган тариф ставкасы исәпләмәсе ($С_{прг}$) h<br>бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат;<br>г) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүм<br>сүндергеч җайланмалар урнаштыруга стандартлашты<br>тариф ставкасы исәпләмәсе ($С_{оу}$); |

| | |
|---|---|
| | д) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүм<br>Мөрәҗәгать итүченең капиталь төзелеш объектында<br>газүткәргеч урнаштыруга стандартлаштырылган тариф ст<br>исәпләмәсе ( $C^{г}_{окс}$ );<br>е) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүм<br>газны исәпкә алу приборы урнаштыруга стандартлаштыр<br>тариф ставкасы исәпләмәсе ($C_{пу}$).<br>ж) тиешле календарь елында башкарылган килешүләр<br>технологик тоташтыру кысаларында газ бүлү һәм газ к<br>объектлары төзелеше буенча чыгымнар турында белешмә<br>нчы кушымта), башкарылган эшләр актлары (КС-2, КС-3,<br>унификацияләнгән формалары), башкарылган эшләр а<br>булмаганда – эш төрләре буенча локаль һәм җыелма<br>хисаплары.<br>3. Методик күрсәтмәләрнең 4 пунктындагы «а» һә<br>пунктчаларында каралган газ кулланучы җайланма<br>технологик тоташтыруга түләүне исәпләү өчен газ бүлү ое<br>тапшыра торган материаллар:<br>а) чираттагы календарь елына түләү билгеләү турында га<br>нче кушымта).<br>Гариза газ бүлү оешмасының вәкаләтле заты тараф<br>имзалана һәм (булган очракта) газ бүлү оешмасының<br>белән беркетелә.<br>б) агымдагы елның 1 октябренә актуаль булган, бухгал<br>исәбенә алу максатларында газ бүлү оешмасының исәп<br>сәясәте;<br>в) тоташтыру (технологик ялгау) чараларын гамәлгә<br>өлкәсендә эшләүче газ бүлү оешмасының структур бүлек<br>хезмәткәрләренең сан исәбе, узган календарь елы<br>хезмәткәрләрнең саны һәм хезмәт хакы турында мәгълү |

| | |
|---|---|
| | булган рәсми статистик хисап формасын теркәп;<br>г) бухгалтерлык балансының һәм эшчәнлекнең җайга сал<br>төрләре буенча чыгымнарны һәм керемнәрне аерым исәпкә<br>финанс нәтиҗәләре турында хисап күчермәләре, к<br>үзгәрешләре турында хисап, акча хәрәкәте турында хисап (а<br>календарь елы өчен) күчермәләре;<br>д) тиешле календарь елы өчен үтәлгән килешүләр б<br>Методик күрсәтмәләрнең 4 пунктындагы «а» һәм<br>пунктчаларында күрсәтелгән очракларда техно<br>тоташтыруларның факттагы саны турында мәгълүмат;<br>е) Методик күрсәтмәләрнең 4 пунктындагы «а» һә<br>пунктчаларында күрсәтелгән очракларда тиешле календар<br>өчен газ куллану җайланмасын тоташтыруга (технологик<br>өчен) чыгымнар турында мәгълүмат, шулай ук агымда<br>алдыннан килгән календарь елы өчен фактта алынмый к<br>торган керемнәр турында мәгълүмат (11 нче кушымта).<br>ж) тиешле календарь елында башкарылган килешүләр б<br>технологик тоташтыру кысаларында газ бүлү һәм газ ку<br>объектлары төзелеше буенча чыгымнар турында белешмәл<br>нчы кушымта), башкарылган эшләр актлары (КС-2, КС-3,<br>унификацияләнгән формалары), башкарылган эшләр ак<br>булмаганда – эш төрләре буенча локаль һәм җыелма<br>хисаплары.<br><br>Гариза һәм документлар бер нөсхәдә тапшырыла.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать<br>тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе<br>тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>җитәкче тарафыннан шәхсән (мөрәҗәгать итүче исем<br>ышаныч кәгазе нигезендә эш иткән зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында белдереп, теркәлгән докум |

| | |
|---|---|
| | исемлеге белән заказлы почта юлламасы итеп.<br>Гариза тапшыру вакыты: 1 октябрьдән дә соңга калмыйча<br>Җайга салынулы оешма тарафыннан кәгазьдә тапш торган, бер биттән артык барлык документларга номерлар с алар тегеп куела, соңгы битендә мөрәҗәгать итүченең м (булган очракта) белән беркетелә һәм җитәкчесенең яки вәкаләтле вәкиленең имзасы белән таныклана.<br>Гариза белән документлар шулай ук газ бүлү oe тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза имзаланган электрон документ рәвешендә, г файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза бланкының электрон формасы һәм документ тапшыру рәвешләре Дәүләт комитетының рәсми сай урнаштырылган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мә күрсәтелергә тиешле хезмәтләр юк. |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул | Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм хезмәте күрсәтүдә катнаша торган башка органнар карама булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле докум каралмаган. |

| | |
|---|---|
| исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны ка итүдән баш тарту нигезләре юк |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмага<br>Түләү (түләү ставкасы) раслау өчен кирәкле документ белдерү белән, газ бүлү оешмасы тарафыннан Дәүләт коми тапшырмау дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе тора, ләкин түләү (түләү ставкалары) күләмен раслау документлар алынган датадан башлап 30 эш көненнән дә и түгел. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми |

| | |
|---|---|
| оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәт көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның макс вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен билгеләнмәгән. |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза тапшырылган көнне. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә те |

| | |
|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландыр биналарда күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү сист белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;<br>мәгълүмат стенды белән.<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чик затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенч видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда г ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, т мәгълүмат Дәүләт комитетына төп керү юлы янынд гражданнарның мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү уры Мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул и инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә мәгълүмат такталарында урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча ч гамәлгә ашырыла:<br>объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтл тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль р яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәк мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>объектларга керә торган урында транспорт чарасына һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-к кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәт ярдәмендә дә;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бо |

| | |
|---|---|
| | инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда<br>күрсәтү;<br>инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтү.<br>тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен к<br>җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнашты<br>хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәменд<br>күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрн<br>Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст ф<br>башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны ка<br>күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шул<br>ишарә телен белә торган башка затны кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль<br>министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрә<br>булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тә<br>раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н но<br>боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торг<br>аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы доку<br>булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торга<br>кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвали<br>алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлату<br>күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләш<br>инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе<br>таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле га<br>эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә<br>электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана<br>мөмкинлеге;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвали<br>башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файда<br>комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка |

| | |
|---|---|
| | күрсәтү |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^{1}$ статьясында каралган гаризаны (комплексы | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәтк түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакы саклануы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрл гамәлләренә прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булмау<br>4) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлы күрсәткечләре:<br>Дәүләт комитеты бинасының җәмәгатьчелек транспорт файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүче документларны кабул итү гамәлгә ашырыла торган ур булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вак турында Дәүләт комитеты мәгълүмат стендларында, «Инт челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муни хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны Интернет челтәрендә Дәүләт комите мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә та мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидла үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен фай алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файда |

| | |
|---|---|
| мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезм порталында шәхси кабинет аша гариза тапшыру һәм хезмәте нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мондый мөмк тудырылганнан соң).<br><br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфунк үзәк (алга таба – КФҮ) аша, күпфункцияле үзәкнең читтән эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файда дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрә буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имза гаризаны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми портал Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада та мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы)<br>Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муни хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша эл документ формасында гариза бирү мөмкинлеген торм ашырганнан соң, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон р бирелә |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза тутыру өлешендә дә;

2) гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү;

3) түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында тәкъдим экспертизасы;

4) гаризаны гамәлдән чыгару турында белдерү;

5) түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында карар кабул итү; ~~яки гаризаны гамәлдән чыгару турында белдерү;~~

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яисә) «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы» аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача формада һәм (яки) хат аша мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, мөрәҗәгать итүченең язмача һәм электрон почта аша килгән мөрәҗәгатеннән тыш, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүченең электрон почта аша килгән мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша мөрәҗәгать кергән көннән соң җиде эш көне узганчы җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүченең язмача мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон документ әйләнеше системасы аша (мөрәҗәгать итүченең әлеге системага тоташтырылган очракта) яисә почта аша (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән системага тоташтырылмаган очракта) язма мөрәҗәгатьне теркәгән көннән җиде эш көне узганчы җавап җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә мөрәҗәгать итүчегә бирелгән консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша, почта буенча, электрон документ әйләнеше системасы аша яисә Татарстан Республикасы рәсми порталының

интернет-кабул итү системасы ярдәмендә Дәүләт комитетына, әлеге Регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә документларны теркәп, Дәүләт комитетының гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлегенә (алга таба – Эшчәнлек бүлеге) технологик ялгау өчен түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында гариза тапшыра.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.3.2. Эшчәнлек бүлеге белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм, теркәлү номеры беркетеп һәм кабул итү көнен күрсәтеп, гаризаны электрон документ әйләнеше системасында терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

гаризаны теркәлгән документлары белән бергә электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада Дәүләт комитеты рәисенә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) (алга таба – рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат)) җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) юнәлдерелгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) теркәлгән документлары белән бергә гаризаны карап тикшерә һәм технологик тоташтыру өлкәсендәге тарифларны җайга салу мәсьәләләрен алып баручы рәис урынбасарына (алга таба – рәис урынбасары) карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.3.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.3.5. Бүлек җитәкчесе гаризаны һәм документларны карый, җаваплы башкаручыны билгели һәм карау өчен аңа җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җаваплы башкаручыга җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Гаризаны гамәлдән чыгару турында белдерү.

3.4.1. Законнарда билгеләнгән срокларда әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны һәм материалларны тулы күләмдә тапшырмаган очракта, җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүчегә түләү (түләү ставкалары) билгеләү өчен кирәкле документларны тапшыру турында хат-белдерү әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Бүлек җитәкчесе хат-белдерүне карый, килештерә һәм рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Рәис урынбасары, хат-белдерүне карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Эшчәнлек бүлеге белгече хат-белдерүне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында гариза кергән көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән, түләү (түләү ставкалары) билгеләү өчен кирәкле документларны тапшыру турында хат-белдерү.

3.4.2. Әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булганда, җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүчегә гаризаны гамәлдән чыгару турында хат-белдерү әзерли һәм аны Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрә.

Бүлек җитәкчесе хат-белдерүне карый, килештерә һәм рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Рәис урынбасары, хат-белдерүне карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Эшчәнлек бүлеге белгече хат-белдерүне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түләү (түләү ставкалары) билгеләүгә гариза кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән, түләү (түләү ставкалары) билгеләү турындагы гаризаны гамәлдән чыгару турында хат-белдерү.

3.5. Түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында тәкъдим экспертизасы.

3.5.1. Законнарда билгеләнгән срокларда әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны һәм материалларны тулы күләмдә тапшырган яки мөрәҗәгать итүчедән әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән хат-белдерү нигезендә документлар алынган очракта, җаваплы башкаручы түләү (түләү ставкаларын) исәпләгәндә исәпкә алынган чыгымнарның нигезле булу-булмавы өлешендә түләү (түләү ставкалары) билгеләү турындагы тәкъдимгә экспертиза үткәрә, аның нәтиҗәләрен эксперт бәяләмәсендә чагылдыра.

Эксперт бәяләмәсе килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә һәм рәис урынбасарына тапшырыла. Эксперт бәяләмәсен Бүлек җитәкчесе һәм рәис урынбасары тарафыннан килештерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы тарафыннан килештерү кәгазе (12 нче кушымта) төзелә, ул, эксперт бәяләмәсен теркәп (мөрәҗәгать итүче соравы буенча) электрон почта аша килештерү өчен мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура түләү (түләү ставкалары) билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елның 10 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эксперт бәяләмәсе, килештерү кәгазе.

3.6. Түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында карар кабул итү.

3.6.1. Җаваплы башкаручы түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында карар проектын әзерли һәм аны Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, рәис урынбасары белән килештерә һәм, алга таба Килештерү комиссиясе утырышында

карау өчен, тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, тикшереп тору һәм алып бару бүлегенә (алга таба – Оештыру бүлеге) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында әзерләнгән һәм Оештыру бүлегенә җибәрелгән карар.

3.6.2. Түләү (түләү ставкалары) билгеләү турындагы карар проекты Дәүләт комитетының Килештерү комиссиясе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Килештерү комиссиясенең составын һәм эшчәнлек тәртибен раслау турында» 2018 елның 14 ноябрендәге 346 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә карала.

Процедураның нәтиҗәсе: Дәүләт комитетының Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе һәм түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында Дәүләт комитеты идарәсе утырышына чыгарылырга тиешле, килештерелгән карар проекты

3.6.3. Түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында карар Дәүләт комитеты идарәсе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең эшчәнлек тәртибен һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында карау өчен мәсьәләләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 231 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә кабул ителә.

3.6.2 һәм 3.6.3 пунктларда билгеләнә торган процедура түләү билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак чордан алда килгән елның 31 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Газ бүлү оешмасында объектларны технологик тоташтыру буенча хезмәтләр күрсәтүдән алынмыйча калган керемнәр барлыкка килгән очракта, алар газ бүлү челтәрләре буенча газны транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларны билгеләгәндә исәпкә алынырга тиеш, чираттагы календарь елына газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү чираттагы елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Процедураның нәтиҗәсе: түләү (түләү ставкалары) билгеләү турында карар, Дәүләт комитеты идарәсе утырышы беркетмәсе.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

Бүлек белгече беркетмәне (беркетмәдән өземтәне) теркәп, карарның таныкланган күчермәсен электрон рәвештә, кулга тапшыру турында белдереп, әлеге карарда үзенә карата түләү (түләү ставкалары) билгеләнә торган мөрәҗәгать итүче адресына почта юлламасы итеп җибәрә.

